

Ярты гасыр элек тозелгән Кочкурово районындагы Татар Умысы авыл клубы ул вакытта Кочкурово районынын гына түгел, республиканын да башка авыл «Мәдәният учагы» белән чагыштырганда масштабы белән аерылып торган.
Умыс авылынын 424 квадрат метр мәйданлы ныклы кирпеч бинасында ял һәм бәйрәм коннәрендә жирле халык та, торле тобәкләреннән килгән күпсанлы татар халкы да жыелган. Кызганычка каршы, үзгәртеп корудан сонгы чорда, тоталь оптимизация нәтижәсендә жирле “Мәдәният үзәге” үз эшен туктата. Сонгы елларда анда намазлар укыла, бирегә, традиция буенча, шәһәрдә яшәүче авыл кешеләре дә даими килә.
Яхшы таш корылма, гомумән, татумыслыларнын жәмәгать күчемсез милегенә сакчыл монәсәбәте аркасында яхшы сакланган булса да, ремонт кирәк. Шуна авыл халкы муниципаль һәм тобәк житәкчелегенә Умыснын “Мәдәният үзәге”н янадан торгызу кирәклеге турында үтенеч белән морәжәгать иткәннәр.
Жирле халыкнын активлыгына тиешле бәя бирергә кирәк. Үз инициативалары буенча авыл халкы һәм тумышы белән бу авылдан булган якташларынын жыелган акчасына Умыста иске мәчет ремонтланган. Берничә ел элек Боек Ватан сугышы елларында тынычлыкны саклаган фронтовиклар һәм тыл хезмәтчәннәре истәлегенә яна монумент куелган.
Күптән түгел Россия Президенты Владимир Владимирович Путин инициативасы белән оештырылган «Мәдәният» илкүләм проекты программасы буенча, Умыс авылы мәдәният сараена капиталь ремонт башланган.
Кочкурово районы админист-рациясендә хәбәр итүләренчә, бүлеп бирелгән акчага, ә ул 36 млн сумнан артык, нигезне ныгыту, түбә һәм фасадны тулысынча янарту, барлык инженер-техник коммуникацияләрне, ишек һәм тәрәзә блокларын алыштыру, заманча санитар узелларны (элек ботенләй булмаган) һәм автоном жылыту системасын жиһазлау планлаштырыла. Иске агач идәннәр урынына реконструкция проектында бетондаштыру һәм махсус туздыруга чыдам плитка салу каралган.
Бер ай эчендә подрядчылар 75 процентка иске түбәне сүтеп, яна түбә урнаштыру

эшләрен башкарган. Параллель рәвештә стеналарны штукатурлау алып барыла. Капиталь реставрацияләнгән бинаны файдалануга тапшыру октябрь-гә планлаштырыла.